## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең Олы Чакмак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында**

02.04.2024ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 02 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Олы Чакмак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 (җиде йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын, көндезге бүлектә укучы студентларга үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1.Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:
-Ф.Садриев урамын ремонтлау (800м);
-авыл юлларын грейдерлау;
-авыл юлларын кардан чистарту һәм аның өчен түләү;
-юл буендагы чүп үләннәрен чабу.
2. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:
-янган лампаларны алыштыру, ремонтлау:
-яңа лампалар сатып алу (10шт.)
3. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:
-зираттагы чүпләрне түгү һәм чүп үләннәрен чабу.
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
-авыл клубының коймасын алыштыру (100м.)
5. Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:
-су буйларындагы чүпләрне ңтүгү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 295 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 157, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 157 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең Олы Чакмак торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Олы Чакмак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын, көндезге бүлектә укучы студентларга үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1.Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

-Ф.Садриев урамын ремонтлау (800м);

-авыл юлларын грейдерлау;

-авыл юлларын кардан чистарту һәм аның өчен түләү;

-юл буендагы чүп үләннәрен чабу.

2. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:

-янган лампаларны алыштыру, ремонтлау:

-яңа лампалар сатып алу (10шт.)

3. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:

-зираттагы чүпләрне түгү һәм чүп үләннәрен чабу.

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

-авыл клубының коймасын алыштыру (100м.)

5. Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:

-су буйларындагы чүпләрне ңтүгү.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Олы Чакмак авыл җирлеге башлыгы** **И.М.Габидуллин**